**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

# КАРАР

28 10 2025 ел № 105

Тукай муниципаль районы Башлыгының
2016 елның 24 февралендәге 20 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 43 статьясы, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистры турында» 2009 елның 9 февралендәге 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль районнары җирле үзидарә органнарына муниципаль районга керүче җирлекләрдән Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын алып бару өчен кирәкле мәгълүмат җыю буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2015 елның 3 ноябрендәге 92-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрын оештыру һәм алып бару тәртибе турында аңлатмаларга үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2019 елның 23 декабрендәге 169од номерлы боерыгы нигезендә һәм кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә

## КАРАР БИРӘМ:

1. Тукай муниципаль районы Башлыгының 2016 елның 24 февралендәге 20 номерлы карарына (2025 елның 8 июлендәге 69 номерлы карар белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.3 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.3. Район Советы аппаратының юридик бүлеге белгече вакытлыча булмаган очракта, әлеге карарның 2.2 пунктында каралган вәкаләтләр район Советы аппаратының юридик бүлеге башлыгы Вәлиева Гөлназ Зөфәр кызы тарафыннан гамәлгә ашырыла, дип билгеләргә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Район Башлыгы вазифаларын башкаручы Р.И. Закиров